# Сабан туйлары башланды!

## Милли бәйрәмгә кайсы районга барырга?

Милли бәйрәм

Гөлүзә **Ибраһимова**

**Район Сабан туйларына танылган артистлар чакыру традициясе бар. Кайсы районга барып, кайсы артистны тыңларга? Кайбер районнарның милли бәйрәм программасы белән кызыксындык.**

Бу елларда Татарстан районнарында Сабан туйлары гөрләп узачак. Ат чабышы, татар көрәше, бәйрәм концерты, милли уеннар, бүләкләр – барысы да булачак. Шуннан соң да Сабан туйлары дәвам итә әле: 19 июньдә – Чаллы һәм Түбән Камада, ә 26 июньдә Казанда республика күләмендәге милли бәйрәм узачак. Бөтенроссия авыл Сабан туен 3 июльдә Мөслимдә үткәрү күздә тотыла.

**Сабада** 12 июньгә билгеләнгән милли бәйрәм сәхнәсендә инструменталь ансамбльләр чыгыш ясаячак. «Сабан туенда «Риваять» ансамбле һәм «Чаллы нуры» коллективы катнаша. Без эстрада артистларын чакырмадык, фольклорга өстенлек бирдек», – диде районның мәдәният бүлеге җитәкчесе **Рөстәм Заһидуллин.**

**Актаныщта** Сабан туе 12 июньдә уза. Бәйрәм концертында үзешчән коллективлар катнашачак. «Бәйрәмгә «Актаныш гармунчылары» дигән зур программа әзерләнә. Төрле төбәкләрдән гармунчылар җыелачак», – дип сөйләде район хакимиятенең мәгълүматлаштыру бүлеге методисты **Эльвира Кузнецова.**

**Буада** бәйрәм 12 июньдә гөрләячәк. «Әнвәр Нургалиевны чакырдык. Шулай ук «Ямьле» коллективы һәм Чувашиядән җырчы Фәридә чыгыш ясаячак», – диде районның мәдәният бүлеге җитәкчесе урынбасары **Миләүшә Гыйматдинова**.

**Мамадыш** Сабан туенда 12 июньдә Айдар Галимов җырлаячак. «Без якташларны да чакырдык. Резеда Кадыйрова, Чулпан Зиннәтуллина, Миңгол Галиев, Ильяс Халиковны көтәбез», – дип сөйләде район мәдәният бүлеге җитәкчесе урынбасары **Зөлфия Никифорова**.



Михаил Захаров фотосы

**Арчада** Сабан туе 13 июньдә узачак. Район хакимиятенең мәдәният идарәсе җитәкчесе **Илфар Әюпов**: «Бәйрәмгә «Казан» бию ансамблен чакырдык. Концертта ИлСаф, Марина Карпова, Алинә Шәрипҗанова, Илгиз Зәкиев, Әмир Әхмәдишин, Руслан Кираметдинов, Ильмира Нәгыймова, Рафис Кәлимуллин катнашачак», – дип хәбәр итте.

**Балык Бистәсендә** 13 июньгә билгеләнгән Сабан туенда эстрада йолдызлары сәхнә тотачак. «Артистлардан Рафил Җәләлиев, Эльмира Гыйльфанова, Чулпан Йосыпова һәм ИлГәрәй катнашыр дип көтелә. Үзебезнең якташлар да җырлап китәр дип өметләнәбез. Гадәттә, Илназ Минвәлиев кайта», – дип сөйләде районның мәдәният бүлеге җитәкчесе урынбасары **Резидә Җәләлова.**

**Сарманда** бәйрәмгә кунакларны 13 июньдә көтәләр. Бирелә кичке Сабан туе да булачак. «Бәйрәмдә ике йөзләп гармунчы катнашында музыкаль парад узачак. Үзебезнең якташларны чакырдык: Зөһрә Шәрифуллина, Вәсим Әхмәтшин, Фәрит Яхин, Дамир Гарифуллинны көтеп калабыз. Кичен Ленин паркында Рифат Зарипов концерт куячак», – диде мәдәният бүлеге җитәкчесе **Гөлназ Латыйпова.**

**Азнакайда** Сабан туе 13 июньдә була. «Көндез эстрада артистларыннан Равил Галиев һәм Зәйнәб Фәрхетдинова чыгыш ясаячак, ә кич белән Фирдүс Тямаев килә», – дип сөйләде мәдәният бүлеге җитәкчесе урынбасары **Светлана Кәлимуллина.**

**Кукмара** районында 13 июньдә үзенчәлекле бәйрәм программасы Манзарас авыл җирлегендә узачак. «Яшүсмерләр һәм хатын-кызлар көрәше дә булачак. Сабан туе батырына ат тапшырылачак. Демографияне үстерү бик актуаль мәсьәлә булганга, райондагы димчеләр клубы яшьләр өчен «димче почмагы» оештыра. Концертка Рифат Зариповны чакырдык», – диде район Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Айгөл Әхмәтшина**.


**Әгерҗедә** Сабан туе 13 июньдә була. Анда «Татарча солянка» концерты әзерләнә.

**Әлмәткә** 13 июньдә Сабан туена Айдар Фәйзрахманов җитәкчелегендәге дәүләт фольклор ансамбле киләчәк. «Концертта шулай ук Актанышның «Агыйдел» ансамбле, Илнат Фәрхуллин, «Зө-Ләй-Лә» кызлары да катнашыр дип көтелә», – диде мәдәният идарәсе җитәкчесе урынбасары **Эльмира Хәсәнова.**

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

# Агрегатор хезмәте – җаваплы эш

## Такси хезмәтләре заказы буенча сервисларны хокукый җайга салу турында.



**Хезмәтләр агрегаторы – ул такси яки шәхси машина йөртүчеләрне эзләү, чакыру һәм түләү өчен мобиль кушымта. Ул бары тик мәгълүмати хезмәтләр генә күрсәтә һәм аның пассажирларны таксида йөртү буенча мөстәкыйль рәвештә хезмәт күрсәтергә хакы юк. Шуның белән бергә, агрегатор хуҗасы сез түләүле хезмәт күрсәтү турында килешү төзегән башкаручы яки хезмәт хакында дөрес яисә тулы булмаган мәгълүмат тәкъдим итү нәтиҗәсендә сезгә китерелгән зыян өчен җавап бирми.**

Агрегатор хуҗасы башкаручы тарафыннан тәкъдим ителгән һәм килешү төзү хакындагы тәкъдимдә урын алган мәгълүматны үзгәртмәгән очраклар искәрмә булып тора (преамбула, «Кулланучыларның хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән 2300-1нче РФ Законының 12 маддәсе 2.1 пункты). Шул рәвешле, таксида барган өчен түләнгән сумма заказ бәясенә туры килмәгән очракта, сез агрегатор хуҗасына зыянны каплау турында таләп белдерергә хокуклы. Язма гаризаны яки дәгъваны:

- кабул итеп алу турында билге куеп, шәхсән үзең тапшырырга (анда дата, кабул иткән затның исем-фамилиясе, әтисенең исеме, вазифасы һәм имзасы булырга тиеш);
- юридик һәм чынлыктагы (булган очракта) адрес буенча исемлек урын алган белдерү кәгазе белән заказлы хат рәвешендә юлларга була.

Сезнең таләпне канәгатьләндерүдән нигезсез рәвештә баш тарткан һәм фикер каршылыклары судка кадәр җайга салынмаган очракта, милеккә бәйле бәхәс Гражданнар Кодексының 11 маддәсе нигезендә суд тәртибендә хәл ителергә мөмкин.

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында»гы РФ Законының 17 маддәсе нигезендә, кулланучыларның хокукларын яклау турындагы дәгъвалар:

- оешма урнашкан урын буенча,
- җавап бирүче шәхси эшкуар булган очракта, аның яшәү урыны буенча,
- сезнең яшәү урыны буенча судка тапшырыла ала.

Салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законы нигезендә, кулланучыларның хокуклары бозылуга бәйле дәгъвалар дәүләт пошлинасыннан азат ителә. Зыянны каплау турындагы таләптән тыш, дәгъва гаризасында сез суд чыгымнарын каплауны, әхлакый зыян өчен компенсация, шулай ук Законның 13 маддәсе 6 өлешендә каралган, суд тарафыннан кулланучы файдасына бирелгән сумманың илле проценты күләмендә штраф түләүне дә таләп итә аласыз.

**ИГЪТИБАР!**

**Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең милеккә бәйле бәхәсләрне карау өчен вәкаләте юк һәм ул хуҗалык итүче субъектлардан административ тәртиптә милеккә кагылышлы таләпләрне үтәүне мәҗбүр итеп куя алмый, чөнки суд органнарына гына шундый вәкаләтләр бирелгән.**

*Мәгълүмат ТР буенча Роспотребнадзор идарәсе материалларына нигезләнеп әзерләнде.*




# Сардана Авксентьева: «Яңа кешеләр» партиясе Татарстанның көченә ышана

**Казанга эш сәфәре вакытында халык мэры Сардана Авксентьева халыкны сентябрь аенда Россиядә узачак сайлауларда катнашырга өндәде.**

Июнь башында Россиядәге иң билгеле хатын-кыз сәясәтчеләрнең берсе, Якутск шәһәренең элекке мэры Сардана Авксентьева Казанга килде. Монда ул «Яңа кешеләр» партиясе активистлары белән очрашты. Сардана Владимировна Яңа кешеләр тарафдарлары белән төбәктәге төп проблемалар һәм аларны чишү юллары турында сөйләште. 2021 елның сентябрь аенда узачак Дәүләт Думасы сайлауларына «Яңа кешеләр» партиясеннән кандидатлар тәкъдим итү турында да сөйләштеләр.

Сардана Авксентьева – халык мэры. 2018-2021 елларда аның шәһәр башлыгы вазифасындагы эшен бөтен ил күзәтте – шуңа күрә аны халык мэры дип атадылар да инде. Россия халкы хакимияттә баеп калырга теләмәгән кеше эшли алуына ышанып бетмәде. Әмма Сардана Авксентьева шәһәр администрациясе карамагындагы кыйммәтле машиналарны шундук аукционга куйды. Шулай ук халык мэры мэрия бәйрәмнәренә миллионлаган сумлык сатып алуларны да бетерде һәм моны эшләргә теләгән түрәне эшеннән куды.

«Тыйнак тормыш рәвеше алып баручы Россия мэрының популярлыгы» мәкаләсендә Якутск мэрының казанышлары турында Британиядә чыга торган абруйлы The Economist басмасы язды. Мәкаләдә язылганча, Россия өчен гадәти булмаган җитәкчелек стиле аны илдә бик популяр итте. Сардана Владимировна социаль челтәрләрдә постларын да үзе язды, мэр вазифасындагы эше турында көн саен сөйләп барды.

«Яңа кешеләр» партиясе лидеры Алексей Нечаев Сардана Авксентьеваның партиядән Дәүләт Думасына кандидат булуына горурлана. Мондый кешеләр Россия халкының тормышын яхшыртырга әзер һәм сәләтле. Хәзер Сардана Владимировна Россия халкын «Яңа кешеләр» партиясе программасы белән таныштыра. Партиядә ул төбәкләр үсеше өчен җавап бирәчәк.

Сардана Авксентьева беренче чиратта Татарстандагы туганнарында булды. Аның бердәнбер кызы Натальяның ире тумышы белән Татарстаннан. Сардана Авксентьева туганлык мөнәсәбәтләрен саклый һәм мөмкинлек чыгу белән якыннары янына килергә тырыша.

«Мин Татарстанга килергә яратам. Монда уникаль атмосфера хөкем сөрә, табигате һәм әлбәттә, кешеләре искиткеч», – диде Сардана Владимировна. Ул «Яңа кешеләр» партиясе Татарстанның Россия тарихы һәм язмышындагы уникаль ролен аңлый дип белдерде. «Татарстан безнең күпмилләтле дәүләтнең көч-куәте», - диде Сардана һәм республика халкын 19 сентябрьдә узачак сайлауларда катнашырга өндәде.

Сардана Авксентьеваны Татарстанда яраталар һәм хөрмәт итәләр. Шуңа күрә аның монда килүе – төбәк тормышы өчен мөһим вакыйга. Илдә хөрмәткә лаек сәясәтченең килүе Сардана Авксентьеваның «Яңа кешеләр» партиясе принципларын хуплавын һәм аның Россия халкы иминлеге өчен эшләргә әзер булуын күрсәтә.